СОВЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
«ГОРОД ИННОПОЛИС»
ул. Спортивная, д.114, г.Иннополис,
Верхнеуслонский район, Республика
Татарстан, 420500

МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕНЕҢ
«ИННОПОЛИС ШӘҺӘРЕ»
СОВЕТЫ
Спортивная ур., 114-нче йорт, Иннополис
шәһәре, Югары Ослан районы, Татарстан
Республикасы, 420500

тел. (843) 212-27-24, e-mail: city@innopolis.ru, www.verhniy-uslon.tatarstan.ru/rus/innopolis.htm

РЕШЕНИЕ КАРАР

20.01.2026 № 8-43

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының «Иннополис шәһәре» муниципаль берәмлеге Советының 19.09.2025 ел № 1-9 карары белән расланган Иннополис шәһәре Башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфасын биләүгә конкурс үткәрү тәртибе турында Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында

Муниципаль хезмәт турында 25.06.2013 ел № 50-ТРЗ Татарстан Республикасы кодексы нигезендә,

«Иннополис шәһәре» муниципаль берәмлеге Советы

Карар итте:

1. Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының «Иннополис шәһәре» муниципаль берәмлеге Советының 19.09.2025 ел № 1-9 карары белән расланган Иннополис шәһәре Башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфасын биләүгә конкурс үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәгә (алга таба – нигезләмә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Нигезләмәнең 8 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«8. Конкурс түбәндәге шартларда уздырыла:

1) Башкарма комитет җитәкчесе вазыйфасына кандидатның булуы:

а) Россия Федерациясе гражданлыгы;

б) югары белем;

в) кимендә бер ел муниципаль хезмәт стажы яисә белгечлек, әзерлек юнәлеше буенча кимендә ике ел эш стажы;

г) идарә эшчәнлеге тәҗрибәсе кимендә биш ел. Идарә эшчәнлеге дигәндә оешма җитәкчесе, җитәкче урынбасары, дәүләт органы, җирле үзидарә органы вазыйфаларында, шулай ук аларның структур бүлекчәләре җитәкчеләре вазыйфаларында эшләү аңлашыла;

д) Башкарма комитет җитәкчесенең вазыйфаи бурычларын үтәү өчен кирәкле күләмдә түбәндәге эшлекле сыйфатлар һәм күнекмәләр:

- Россия Федерациясе Конституциясен, Татарстан Республикасы Конституциясен, федераль законнарны һәм Татарстан Республикасы законнарын, шул исәптән аның компетенциясенә һәм башкарма комитетны алып баруга кагылышлы мәсьәләләрне җайга сала торган башка муниципаль хокукый актларны да кертеп,

һөнәри белемнәр булу;

- муниципаль берәмлекнең социаль-икътисадый үсеше стратегиясен һәм аңа йөкләнгән вәкаләтләрне гамәлгә ашыру буенча Башкарма комитет эшчәнлеге юнәлешләрен билгеләү, әлеге эшчәнлекнең яңа формаларын һәм ысулларын эзләү, аларны гамәлгә ашыру механизмнарын эшләү сәләте;

- үз эшчәнлегеңне, Башкарма комитет, аның Башкарма комитет җитәкчесенә буйсынучы органнары эшчәнлеген планлаштыру, оештыру һәм анализлау сәләте;

- этик нормаларны белү һәм аларны хезмәт аралашуында куллану сәләте;

2) кандидатның муниципаль хезмәткә керү һәм аны узу өчен муниципаль хезмәт турындагы законнарда билгеләнгән чикләүләр булмавы».

2. Әлеге карар Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында түбәндәге адрес буенча басылып чыккан көннән үз көченә керә: http://pravo.tatarstan.ru шулай ук Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында түбәндәге адрес буенча урнаштыру юлы белән халыкка игълан ителергә тиеш: http://verhniy-uslon.tatarstan.ru, һәм Иннополис шәһәре мэриясе бинасында урнашкан мәгълүмат стендында халыкка игълан ителергә тиеш.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны «Иннополис шәһәре» муниципаль берәмлеге Советының законлылык, хокук тәртибе, регламент һәм депутат этикасы буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Иннополис шәһәре Мэры вәкаләтләрен вакытлыча башкаручы И.Р. Хуззятов